# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге составына керүче Кыр Тәүгелдесе торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

18.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Кыр Тәүгелдесе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Кыр Тәүгелдесе авылында су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау,- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү),- ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 18 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегендә 91 катнашучы, тавыш бирүдә катнашучылар саны 51 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 49 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Кыр Тәүгелдесе авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип таныырга.

2. «Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Кыр Тәүгелдесе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Кыр Тәүгелдесе авылында су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау,- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү),- ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип таныырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Кыр Тәүгелдесе авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ___________ Д.Д.Абдрахманова

Яңа Чәчкап авыл җирлеге
башлыгы ___________________ Д.Д.Абдрахманова